| Каралган | Килешенгән | Раслыйм |
| --- | --- | --- |
| МБ житәкчесе | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең УТЭБДУ | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ директоры |
| ______ /Калинина М.Б./ | ______ /Сәгъдиева Г.Ф./ | ______ / Әхмәдшина ... |
| Беркетмә № 1 | «25»август 2014 ел. | Приказ № 94 |
| «25»август 2014 ел. | | «27»август 2014 ел. |

уку фәненнән

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы

«Яңа Мәлкән ТГБМ» ГББМУ

## Калинина Мәкфия Биктимер кызы, 1 категорияле укытучы

уку, 1 нче сыйныф

Педагогик совет

утырышында каралган.

беркетмә № 1

« 25 » август 2014 ел.

2014 – 2015 нче уку елы

## Аңлатма язуы

1 класс буенча әдәби укудан эш программасы якынча гомуми башлангыч белем программасы нигезендә эшкәртелде. Р.Г.Вәлитова,С.Г.Вагыйзов программаларына нигезләнеп һәм башлангыч белем бирү Дәүләт стандартларының Федераль компонентына нигезләнеп төзелде. Программада Мәгариф министрлыгы тәкъдим иткән "Татарстан мәктәпләрендә татар телен дәүләт теле буларак укыту эчтәләгенә таләпләр минимумы" исәпкә алынды.

**Максатлар**:

укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үстерү һәм телне аралашу чарасы буларак барлык ситуацияләрдә кулланырга өйрәтү;
аралашу һәм танып белү чарасы булган телне аңлы үзләштерүгә ирешү;
балаларны текст, китап белән эш итү алымнарына өйрәтү;
коммуникатив сөйлом осталыгы һәм иҗади сәләт арасында бәйләнеш булдыру;
укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү, аларда аралашу культурасы күнекмәләре тәрбияләү.

**Бурычы**— укучыларны татар теленең график системасы төзелеше һәм функциясенең гомуми закончалыклары белән танышу нигезендә башлангыч уку һәм язуга өйрәтү. Бу үз чиратында укучыларда тел турында белем һәм күнекмәләрнең формалашуына нигез булып тора.

## Курсның төп сораулары

Грамотага өйрәнү чорында график эшчәнлекне үзләштерү — I сыйныф укучысының төп бурычы. Чөнки бу эшчәнлек нәтиҗәсендә балаларда уку һәм язу күнекмәләре формалаша.

Грамотага өйрәнү процессында балаларда татар теле системасының төп тел берәмлекләре (аваз, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст) турында күзаллау туа, фонематик ишетү һәм авазны әйтү культурасы үсә. Алар, беренчедән, төрле шартлы модельләр (квадрат, түгәрәк) һәм махсус транскрипция билгеләре системасы нигезендә сүзнең аваз формасын күз алдына китереп әйтә алу; икенчедән, сөйләмнең фонетик язуын тиешле басма яки язма хәрефләргә күчерү; өченчедән, сүзнең хәреф моделе буенча аваз формасын төзү эшчәнлеген, ягъни уку күнекмәләрен үзләштерәләр. Шул ук вакытта укучылар язма хәрефләрне, аларны иҗекләргә, сүзләргә тоташтырып язу технологиясен дә үзләштерәләр.

«Әлифба» һәм шулай ук «Язу дәфтәре»ндә аваз һәм хәрефләрне өйрәнү эзлеклелеге татар графикасының позицион (иҗек) принцибына нигезләнгән.

Сузык авазлар һәм аларга билге булып килгән хәрефләр беренче чиратта өйрәнелә, чөнки алар иҗек төзи, шуның нигезендә укучылар уку технологиясе белән таныша.

Сузыклардан соң сонор тартыклар өйрәнелә. Бу аларның яңгырау һәм саңгырау парларының булмавы, яңгырашы ягыннан сузык авазларга якын торуына бәйле. Нәкъ менә шушы тартык аваз төркемнәре аша графиканың позицион принцибы төшенчәсе кертелә, ә бу үз чиратында хәрефнең үзенчәлеген янындагы хәрефләр йогынтысында гына белергә мөмкинлекне аңлата. Моны алда өйрәнелгән сузык аваз хәрефләре ярдәмендә күрсәтергә мөмкин: а, ы, у, о хәрефләре — тартык авазның калынлыгын; ә, э, и, ү, ө, е хәрефләре нечкәлеген белдерә. Калын сузык аваз хәрефләре янында тартыкларның — калын, нечкә сузык аваз хәрефләре янында нечкә әйтелүен төшендерү аеруча мөһим.

Моннан тыш, кыска [й] авазын өйрәнү е, ю, я хәрефләре ике аваз кушылмасына, ягъни [й] һәм тиешле сузыкка билге булып килүе белән дә танышырга ярдәм итә.

Алга таба тартыкларның яңгырау һәм саңгырау парларын өйрәнгәндә, мисалларга таянып, балалар язуда тартыкларның калынлык һәм нечкәлекләрен белдерү кагыйдәләрен ныгыталар.

Соңыннан алар аеру билгеләре [ь,ъ] булган сүзләргә аваз анализы ясарга һәм ул сүзләрне укырга өйрәнәләр, шуннан соң гына парсыз шаулы тартыклар белән танышалар, аларның язылыш үзенчәлекләрен үзләштерәләр.

I сыйныф укучысы кыска гына вакыт эчендә өйрәнелә торган аваз еш кулланылган сүзләрне, текстларны укырга өйрәнә, нәтиҗәдә хәрефләрне тиешле авазларга күчерә.

«Әлифба»да уку өчен махсус төзелгән текстлардан тыш, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән һәм балаларда танып белү эшчәнлеген формалаштырырга ярдәм итә торган башка жанрдагы әсәрләр: шигырь, табышмак, мәкаль, әйтем, тизәйткеч, санамышлар да урын алган. Грамотага өйрәтү дәресләрендә балаларның фонематик ишетеп аңлау һәм аваз культурасы үсешенә сүзләрне «үстерү» һәм сүзләрне үзгәртеп төзү алымнарын куллану нәтиҗәсендә ирешелә. Сүзләрне «үстерү»нең асылы сүзнең авазлар санын акрынлап үстерә баруда, бу башлангыч сүзнең үзгәрүенә һәм яңа сүзләр ясауга китерә. Мәсәлән: бал — бала — балан — баланлы — баланлык. Бу дәреслектәге лексик материалны баетып кына калмый, ә укучыларда күзәтүчәнлекне үстерүгә һәм аңлап уку техникасын формалаштыруга җирлек тудыра. Мондый чылбырдагы сүзләрне уку берьюлы ике дәрәҗәдә башкарыла: а) иҗекләп (җырлап, йөзмә, салмак) уку; ә) авазларны дөрес әйтеп (орфоэпик), басымнарны дөрес куеп уку.

Шулай ук сүзләрне үзгәртеп төзү алымы да кулланыла, бу укучыларга сүзгә бер аваз өстәү яки аның бер авазын үзгәртү нәтиҗәсендә сүзнең мәгънәсе тулысынча үзгәрүне күзәтергә мөмкинлек бирә, мәсәлән: көн — төн, бала — балан һ.б.

Бу этапта җиде яшьлек балалар алдында торган төп бурыч булып, басма һәм язма хәреф билгеләренең формаларын үзләштерү тора. Басма һәм язма хәрефләр системасына структур-системалы якын килү нәтиҗәсендә, хәрефләрне төзү максатыннан, аларның элемент-өлгеләре эшләнде. Аларны кулланып, укучы үз куллары белән өйрәнелә торган хәреф формасын мөстәкыйль төзи алуга ирешә.

I сыйныфта балалар укырга өйрәнү белән параллель язарга да өйрәнә. Укудан аермалы буларак, язу кул хәрәкәте компоненты булып тора. Язуның график күнекмәләре (хәрефләрнең рәвешләрен, тоташ язу, язу тизлеген үзләштерү) — хәрәкәт күнекмәләренең бер төре. Язу процессында һәр авазның язма хәрефен күңелдә тудырырга, бу очракта шул аваз нинди хәреф билгесе белән белдерелүен искә төшерергә һәм кул чугы мускулларын хәрәкәтләндереп, шул хәрефне дөрес язарга кирәк. Катлаулы кул хәрәкәте эшчәнлеге буларак, язуны автоматлашу дәрәҗәсенә җиткерү нәтиҗәсендә график күнекмә барлыкка килә.

Язарга өйрәтү, уку кебек үк, өч (әзерлек, төп (аваз-хәреф) һәм йомгаклау) этаптан тора.

Әзерлек этабында I сыйныф укучылары график системаның структур берәмлекләре, яки татар алфавитының язма хәрефләре элементлары белән таныша. Язарга өйрәнүнең төп этабында (ул әлифба чорына туры килә) балалар барлык язма хәрефләрне иҗекләрдә, сүзләрдә, җөмләләрдә кушып (тоташ) язу күнекмәләрен алалар.

Йомгаклау этабында балаларның язуларындагы график һәм каллиграфик хаталар төзәтелә, график күнекмәләр ныгытыла.

## Предметның мәктәпнең укыту планындагы урыны

Яңа Мәлкән МТГБМ нең укыту планында әдәби уку фәнен өйрәнү өчен 66 сәг. Бирелгән.Шуның 42 сәгате(21атна) грамотага өйрәнү чорына, ә 24сәгате(12атна) татар теленә бирелә.Татар теленнән укыту программасы ТР  БУПна нигезләнеп төзелгән.

**Программа эчтәлеге**

| № | Бүлекләр | Сәг.саны | Үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр. |
|---|---|---|---|
| **1** | **Әзерлек чоры** | **9сәг** | 1. Элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны **аңлый**, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын **атый һәм формалары буенча аера белергә**;.<br>2. Рәсем, график модель яки тиешле фишкалар кулланып, беренчедән, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2 — 4 сүздән торган **җөмләләр** һәм 3 — 4 җөмләдән торган **хикәя төзи**; икенчедән, парта артында **дөрес утыра** һәм язма әсбаплардан дөрес **файдалана**, алгоритм буенча яки тактлап язма хәрефләрнең барлык элементларын да **дөрес яза белергә тиешләр.** |
| **2.** | **Әлифба чоры** | **33сәг** | 1. Татар теленең авазларының сузык (ачык авыз символы белән бирелгән), ягъни җырлана торган аваз һәм тартык, ягъни җырланмый торган; әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала/ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә- калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;<br>- сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;<br>- сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;<br>- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен;<br>- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүләрен, ярдәмче сүзләр сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын;<br>- әйтмә сөйләмнең текст һәм җөмләләргә бүленүен, аларны график сурәтләп булу мөмкинлеген;<br>элемент-сызыклар һәм элемент-өлгеләрнең басма һәм язма хәрефләрнең график системасының структур (төзелеш) берәмлекләре булуын;<br>- һәр басма һәм язма хәреф формасының тиешле урын-сан мөнәсәбәтендә урнашкан элементлардан торуын **аңлый белергә тиеш.**<br>2. Укучылар сүз башыннан башлап, андагы һәр авазны көчлерәк итеп **билгели бара**, берсен аерып алып аңа **характеристика бирә**;<br>- анализ вакытында тартыкларның яңгырау-саңгыраулыгын билгеләү алымнарын **куллана;**<br>- сүзне иҗекләргә **бүлә**;<br>- схемалардан сүзнең аваз язылышын иҗекләп һәм орфоэпик **дөрес итеп укый**;<br>- схемалардагы һәм «Әлифба» текстларында бирелгән хәреф язуын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп **укый;**<br>- сүзнең аваз формасын шартлы график формадан хәреф формасына һәм киресенчә **үзгәртә;**<br>- элемент-шаблоннар нигезендә басма һәм язма хәрефләрне **төзи һәм анализлый;** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | - аерым график биремне үтәү дәвамында дөрес итеп утыра һәм язма әсбаплардан **файдалана ала;**<br>- билгеле бер алгоритм буенча хәрәкәт элементлары нигезендә хәрефләр **яза;**<br>- иҗекләрдә һәм сүзләрдә тоташтыруның өч алымын **үти;**<br>- тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген **йомшарта;**<br>- күчереп язганда һәм диктант вакытларында җөмләләрне һәм үз исемнәрен **дөрес яза;**<br>- бизәк-бордюрлар **ясый ала белергә тиешләр**. |
| **3.** | **Әлифбадан соңгы чор** | **24сәг** | 1. Туган телнең сөйләм төзелешен **аңлый**, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләрен образлы **күзаллый**;<br>- татар алфавиты басма һәм язма **хәрефләренең график системасын**;<br>- һәр хәрефнең элемент **формаларын;**<br>- дөрес утыру һәм язма әсбапларны куллану **кагыйдәләрен белергә тиеш.**<br>2. Һәр укучы үзенә генә хас темпта басма һәм язма текстларны офоэпик нормаларга туры китереп **укый;**<br>- текстның аерым бер өлешләрен **сөйли** (2 — 3 җөмлә белән) ;<br>- укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга **җавап бирә;**<br>- тыңланган текстка **исем куша**;<br>- төрле методик шартларда: 1) басма яки язма текстны күчереп язганда, 2) хәтер буенча яки 3) укытучы әйтеп яздырган вакытта, үзләштерелгән алгоритмга туры китереп аерым да, җөмлә эчендә дә сүзләрне өзмичә **язу күнекмәләрен үзләштерә** һәр укучы, шәхси мөмкинчелеген истә тотып, **язу темпын арттыра белү кебек эш төрләрен башкара белергә тиеш**.<br>3**. О, ө** хәрефләрен беренче иҗектә генә **язу;**<br>- әйтмә һәм язма сөйләмне тел берәмлекләренең төзелеше турында беренче сыйныф укучыларында формалашкан күзаллау нигезендә **анализлау** һәм тиешле символлар белән **модельләштерү;**<br>- тыныш билгеләренә игътибар итеп. иҗекләп, орфоэпик, бәйләнешле итеп уку алымнарын **куллану;**<br>- хәрефләрне язуда тоташ һәм тиз итеп язу алымнарын **тормышка ашыру**;<br>- татар теленең позицион принцибына нигезләнеп, **[гь] [кь]** авазларын язуда **белдерү** турында **үзләштергән белем һәм күнекмәләрен уку эшчәнлегендә һәм көндәлек тормышта кулланырга өйрәнергә тиешләр.** |

**Әзерлек чоры**

**Уку**

Әкият текстын тыңлау. Иллюстрацияләрнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мөнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү.

Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр җыелмасы буларак, икенчендән, нәрсә турында да булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. Конкрет җөмләләр белән текстның график моделе арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау. Рәсем белән бирелгән хикәяне исемләү (исем кушу). Текст төзү элементлары. Тәкъдим ителгән график моделе буенча хикәя эчтәлеген сөйләү.

Укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән укытучы сорауларына җавап бирү. Текст эчтәлеген сайлап алып сөйләү, шигырь ятлау.
Телнең структур берәмлеге буларак сүз турында башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең элемент-өлгеләре белән танышу.

**Әзерлек чоры ахырына балалар**:
1. Элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны **аңлый**, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын **атый һәм формалары буенча аера белергә**;.
2. Рәсем, график модель яки тиешле фишкалар кулланып, беренчедән, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2 — 4 сүздән торган **җөмләләр** һәм 3 — 4 җөмләдән торган **хикәя төзи**; икенчедән, парта артында **дөрес утыра** һәм язма әсбаплардан дөрес **файдалана**, алгоритм буенча яки тактлап язма хәрефләрнең барлык элементларын да **дөрес яза белергә тиешләр.**

**<u>Әлифбачоры</u>**

**Уку**

Сузык **[а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө]** авазларының сүздә төрле позициядә килгән һәм аерым кулланылган очрактагы артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. График схема буенча сузык авазны әйткәндә, сузыкка басым куеп әйтү. Сүзнең график схемалары буенча сүзне көйләп,иҗекләргә бүлеп салмак һәм орфоэпик дөрес уку. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү.

Схемада сузык авазны башта түгәрәк, соңыннан транскрипция билгесе белән билгеләү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өйрәнелгән сузык аваз кергән сүзләр сайлау.

Элемент-өлге ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни «киеме» буларак образлы күзаллау булдыру.

Укытучы укыган текстны тыңлау, эчтәлеген аңлау, куелган сорауларга җавап табу, ишетеп кабул ителгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү.

**Парсызсонортартыкавазлар**

**[м, н, л, р, й, ң]** сонор тартык авазлары. Бирелгән авазларның артикуляциясе : үпкәдән килә торган һава агымы бер сөйләм органында, мәсәлән иреннәрдә, тешләрдә, тел алдында, тел уртасында, тел артында киртәгә яки тоткарлыкка очрый, бу авазларны әйткәндә тон өстенлек итә, шау катнаша гына. Шуңа күрә ул авазларны ярым сузыклар дип тә йөртәләр.

Калын һәм нечкә яңгырашлы сүзләрдә сонор тартык авазлар әйтелешен чагыштыру; язуда аларның калын яңгырашын калын сузык аваз хәрефләре **(а, у, о, ы)** белән **(ма, му)**, нечкә яңгырашын нечкә сузык аваз хәрефләре **(ә, и, ө, ү, э)** белән белдерү. Сүздә һәр авазны аерып әйтү алымы. Рәсем һәм схема белән бирелгән сүзләргә аваз анализы. Анализлана торган сүз составына кергән аерым аваз артикуляциясе. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат белән билгеләү.

Чагыштыру өчен бирелгән сүзләрдәге **(мал-мәл)** авазларның аермалы билгеләренең мәгънә функциясенә ия булуын билгеләү.

Сонор авазларны белдерүче басма баш һәм юл хәрефләрнең формаларын үзләштерү. Ябык иҗекләрне **(ай)** һәм калын һәм нечкә яңгырашлы кушылмаларны **(ма, мә, му, мү һ.б.),** шулай ук парсыз тартык авазлар уртада һәм ахырда булган сүзләрне **(май, малай)** уку. Сүзләрне иҗекләп уку белән чагыштырып, орфоэпик уку һәм әйтү алымы.

**Сүзбашындаһәмсүзуртасында |й] авазы**

**Я, е, ю** хәрефләренең ике авазга **[йа], [йә], [йы], [йә], [йу], [йү]** билге булып килүләре: **яра, ял, юл, куян, баян.**

Аваз-хәреф схемаларын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп уку. Шартлы билгеләр һәм басма хәрефләр нигезендә сүзнең аваз формасын график формага күчерү процессын күзәтү.

**Я, е, ю** хәрефләрен куллану кагыйдәләрен үзләштерү. Бу хәрефләр кергән сүзләрне һәм иҗекләрне уку. Баш һәм юл басма хәреф формаларын төзү.

**Яңгыраућәмсаңгыраупарларыбулгантартыклар**

Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны калын һәм нечкә яңгырашын билгеләү: нечкәлек яңгырау, саңгырау (**[д-т],[з-с],[г-к],[гъ-къ]** һ.б.) парларның үзара мөнәсәбәтен ачыклау. Мәсәлән **бар-бар, бар-пар** һ.б. Өйрәнү тәртибендә басма хәреф формаларын үзләштерү.

Авазларында аерма булган сүзләрне, яңгырау һәм саңгырау тартык авазлардан башланган сүзләрне әйтеп карау, чагыштыру күнегүләре **(бар-пар).**

Аваз-хәреф схемалары нигезендә авазларны аеру, иҗекләр, сүзләр, текстлар уку.

Башлангыч сүзне һәм **сүзнең авазын алмаштыру** яки **аваз өстәү юлы** белән ясалган яңа сүзләрне **(бур-бура-буран)**, шулай ук ике яктан да бертөрле укыла торган **(ана)** сүзләрне уку. Табышмаклар уку һәм аларның җавабын табу. Тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү.

Аваз. иҗек.сүз.җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау формалаштыру.

**Аерубилгеләребулыпторган ь һәм ъ тансоң [й] авазы**

Язуда аеру билгеләре булып торган **ь** һәм **ъ** һәм сузык аваз хәрефләре ярдәмендә **[й]** авазының язуда бирелешен **(ь+е, я, ю; ъ+е, ю, я)** аңлату. (**Я, е, ю** хәрефләре алдындагы иҗек калын сүзләргә **(альяпкыч) ъ** билгесе, **алдагы** иҗек нечкә сүзләргә **(дөнья) ь** билгесе куелуын аңлатыла).

Аеру билгеләре һәм сузык аваз хәрефләре белән белдерелгән **[й]** авазлы сүзләрнең аваз анализы. **[Й]** авазы кергән сүзләрнең аваз схемасын уку. аны хәреф формасына үзгәртү, соңыннан башта иҗекләп, аннан соң орфоэпик дөрес итеп уку.

**Ь, ъ** билгеләренең басма хәрефләрен төзү һәм аларның формаларын үзләштерү.

(Бу билгеләрнең [гъ], [къ] авазларының калынлыгын белдерү өчен дә кулланылуын аңлату **(игътибар, тәкъдим).** Калын **[гъ]** һәм **[къ]** авазлары булган сүзләрнең калынлыгын белдерү өчен язуда калын сузык аваз хәрефләре куланылуын, әйткәндә, иҗек нечкәлеген белдерү өчен, ахырдан **ь** билгесе куелуын ассызыклан үтәргә кирәк. Мәсәлән **мәкаль** сүзендә **[къ]** калын кече тел тартыгы, аның калынлыгын белдерү өчен **к** дан соң **а** язабыз, укыганда **[мәкъәл]** дип укыйбыз, икенче иҗекне нечкә итеп уку өчен сүз ахырына **ь** билгесе куябыз.)

**Парсыз тарлык авазлар**

Парсыз **[х, һ, щ, ц]** тартыклар артикуляциясе. Бу авазларның характеристикасы. Парсыз тартык авазлар кергән иҗекләр һәм сүзләр, текстлар уку. Текстның эчтәлеген үзләштерү. Эчтәлеген сөйләү. Басма хәрефләрнең формаларын үзләштерү.

**Әлифбачорыныңахырынабалалар:**

1. Татар теленең авазларының сузык (ачык авыз символы белән бирелгән), ягъни җырлана торган аваз һәм тартык, ягъни җырланмый торган; әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала/ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә- калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;

- сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;
- сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;
- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен;
- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүләрен, ярдәмче сүзләр сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын;
- әйтмә сөйләмнең текст һәм җөмләләргә бүленүен, аларны график сурәтләп булу мөмкинлеген;
элемент-сызыклар һәм элемент-өлгеләрнең басма һәм язма хәрефләрнең график системасының структур (төзелеш) берәмлекләре булуын;
- һәр басма һәм язма хәреф формасының тиешле урын-сан мөнәсәбәтендә урнашкан элементлардан торуын **аңлый белергә тиеш.**
2. Укучылар сүз башыннан башлап, андагы һәр авазны көчлерәк итеп **билгели бара**, берсен аерып алып аңа **характеристика бирә**;
- анализ вакытында тартыкларның яңгырау-саңгыраулыгын билгеләү алымнарын **куллана;**
- сүзне иҗекләргә **бүлә**;
- схемалардан сүзнең аваз язылышын иҗекләп һәм орфоэпик **дөрес итеп укый**;
- схемалардагы һәм «Әлифба» текстларында бирелгән хәреф язуын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп **укый;**
- сүзнең аваз формасын шартлы график формадан хәреф формасына һәм киресенчә **үзгәртә;**
- элемент-шаблоннар нигезендә басма һәм язма хәрефләрне **төзи һәм анализлый;**
- аерым график биремне үтәү дәвамында дөрес итеп утыра һәм язма әсбаплардан **файдалана ала;**
- билгеле бер алгоритм буенча хәрәкәт элементлары нигезендә хәрефләр **яза;**
- иҗекләрдә һәм сүзләрдә тоташтыруның өч алымын **үти;**
- тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген **йомшарта;**
- күчереп язганда һәм диктант вакытларында җөмләләрне һәм үз исемнәрен **дөрес яза;**
- бизәк-бордюрлар **ясый ала белергә тиешләр**.

**<u>Әлифбадан соңгы чор</u>**

Төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен формалаштыру. Текстагы «авыр» (озын һәм таныш булмаган) сүзләрне укыганда иҗекләп укырга мөмкин. Җөмләнең тыныш билгеләренә карап җөмләләр арасында тукталыш (пауза) ясау. Хикәяләү, сорау, тойгылы җөмләләрнең интонациясен бирү. Укылган текст буенча бирелгән сорауларга тулы җавап бирү. сайлап алып эчтәлеген сөйләү, текстның башын, ахырын үзгәртү, аңа яңа исем бирә белү күнекмәләренә ия булу.

Текстның **1) башлам** (вакыйга нәрсәдән башалана). **2) төп өлеш** (катнашучы-геройлар белән нәрсә була), **3) йомгаклауга** (нәрсә ничек тәгалләнә) туры килә торган кисәкләрен табу һәм уку. Текста сурәтләнгән вакыйгаларга укучы баланың һәм авторның мөнәсәбәтен белдерә белү.

**Әдәби уку программасы эчтәлеге.**

Балалар Әлифбадан әдәби укуга сиздермичә генә, эзлекле рәвештә күчәргә тиеш. Кече яшьтәге мәктәп балалары аңлап укуның беренчел күнекмәләрен ала, халык авыз иҗатының жанрлары белән таныша һәм аларны тормышта кулланырга өйрәнә. Аптыраткыч-алдавыч, әйләнмәле, чылбыр әкиятләрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен аера, авторларның чәчмә һәм шигъри текстлары белән таныша. Халык авыз иҗаты һәм шагыйрьләрнең шигъри әсәрләре аша, юл ахырындагы охшаш сүзләргә нигезләнеп, рифма, кабатлаулар, сәнгатьлелек турында беренчел кузаллау булдырыла.

Кыска текстлар һәм аларга ясалган иллюстрацияләрне чагыштырып, әдәби образның сәнгатьнең төрле төрләрендә тасвирлануы аңлатыла.

Беренче сыйныфны тәмамлаганда бала текстны аңлап укырга һәм аның эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белергә тиеш (дәреслектә бирелгән конкрет сорауларга җавап бирү формасында).

Балаларда халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау булдырыла, алар проза һәм поэзиянең үзенчәлекләрен танып беләләр, “автор”, “әсәрнең исеме” төшенчәләре бирелә, әсәрдәге персонажларны танып әйтә алалар.

Беренче сыйныфтагы төп бурыч — укуга кызыксыну тәрбияләү һәм дөрес уку күнекмәләре булдыру — икенче сыйныф өчен дә актуаль булып кала.

Программа әдәби әсәрләр белән эшләү юллары, алымнары белән таныштыра, шул ук вакытта укытучыга иҗади эшләү мөмкинлеге дә калдыра.

Шигырь һәм проза. Шигъри һәм чәчмә әсәрләр турында гомуми кузаллау булдыру. Әдәби әсәрнең исеме, авторы (язучы, шагыйрь), халык авыз иҗатында билгесезлек (авторы юк).

Халык авыз иҗаты һәм әдәбият

Халык авыз иҗаты турында гомуми кузаллау булдыру. Авторның булмавы, телдән сөйләм, практик-уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр. Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләр. Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек формаларын практик яктан үзләштерү.

Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикере (әсәр исеме, геройларга характеристика, авторлар бәяләмәсе).

Әсәрнең эмоциональ тоны

Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләр. Әсәрләрне китаптан кычкырып, яттан укыганда эмоциональ характерны чагылдыра белү. Тавыш төсмерләре: интонация, тон, тавыш көче, тембр, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләр, ымнарны дөрес бирә алу.

**Грамотага өйрәтүнең йомгаклау чорында беренче сыйныф укучылары:**

1. Туган телнең сөйләм төзелешен **аңлый**, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләрен образлы **күзаллый**;
- татар алфавиты басма һәм язма **хәрефләренең график системасын**;
- һәр хәрефнең элемент **формаларын;**
- дөрес утыру һәм язма әсбапларны куллану **кагыйдәләрен белергә тиеш.**

2. Һәр укучы үзенә генә хас темпта басма һәм язма текстларны офоэпик нормаларга туры китереп **укый;**
- текстның аерым бер өлешләрен **сөйли** (2 — 3 җөмлә белән) ;
- укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга **җавап бирә;**
- тыңланган текстка **исем куша**;
- төрле методик шартларда: 1) басма яки язма текстны күчереп язганда, 2) хәтер буенча яки 3) укытучы әйтеп яздырган вакытта, үзләштерелгән алгоритмга туры китереп аерым да, җөмлә эчендә дә сүзләрне өзмичә **язу күнекмәләрен үзләштерә** һәр укучы, шәхси мөмкинчелеген истә тотып, **язу темпын арттыра белү кебек эш төрләрен башкара белергә тиеш**.

3**. О, ө** хәрефләрен беренче иҗектә генә **язу;**
- әйтмә һәм язма сөйләмне тел берәмлекләренең төзелеше турында беренче сыйныф укучыларында формалашкан күзаллау нигезендә **анализлау** һәм тиешле символлар белән **модельләштерү;**
- тыныш билгеләренә игътибар итеп. иҗекләп, орфоэпик, бәйләнешле итеп уку алымнарын **куллану;**
- хәрефләрне язуда тоташ һәм тиз итеп язу алымнарын **тормышка ашыру**;

- татар теленең позицион принцибына нигезләнеп, **[гь] [кь]** авазларын язуда **белдерү** турында **үзләштергән белем һәм күнекмәләрен уку эшчәнлегендә һәм көндәлек тормышта кулланырга өйрәнергә тиешләр.**

**Әдәби сәнгатьлелек чаралары**

Текстны анализлау барышында сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел кузаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: рифма, ритм төшенчәсе бирү.

Әдәби жанрлар

Жанрлар турында гомуми кузаллау булдыру:

Хикәя. Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү.

Шигырь. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрь матурлыкны тоя белергә өйрәтә. Рифма белән танышу: аны таба, куллана белергә күнектерү.

Библиографик культура. Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга өйрәтү: “Эчтәлек” битеннән кирәкле әсәрне тиз генә эзләп табу.

Уку күнекмәләре. Укучыларны тиз һәм йөгерек укырга гадәтләндерү. Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү.

**1нче сыйныф өчен программа таләпләре:**

- балада дөрес һәм йөгерек укуга ихтыяҗ булдыру (текстлар балаларга ошарга, тиз истә калырга, күбрәк уку теләге, уку барышындагы кыенлыкларны җиңү теләге уятырга тиеш);
- алты-җиде яшьтәге балада беренчел уку күнекмәләре булдыру (шигъри әсәрләр белән бала кечкенәдән — балалар бакчасында йөргәндә үк таныш була, шигырь юлларының кыскалыгы укуга теләк уята, рифма аңа сүзне табарга ярдәм итә, үз көченә ышаныч уята, ритм кечкенә балаларның яшәү рәвешенә туры килә);
- әдәбият үсешенең халык авыз иҗатыннан язма формаларга күчү эзлеклелеге аңлатыла (беренче сыйныф укучылары халык авыз иҗатының төрле формалары: фольклорның кече жанрлары, әйләнмәле, чылбыр, алдавыч әкиятләр, төрле авторларның балалар өчен язылган шигырьләре, кыска хикәяләр белән таныша );
- алты яшьлек баланың әхлакый һәм эстетик үсеш дәрәҗәсе иң алгы планда тора (халык авыз иҗаты һәм әдәби әсәрләрнең сюжеты уен характерында бара; күпчелек текстлар балаларда юмор хисе тәрбияләүгә юнәлтелә).

**1 нче сыйныфны тәмамлаганда, укучыларның белеменә, эш осталыгына, һәм күнекмәләренә таләпләр:**

- әсәрне иҗекләп, аерым сүзләрне дөрес әйтеп укый белү;
- текст эчтәлеген аңлау;
- проза һәм шигъри әсәрләрне аера белү;
- фольклор әсәрләрен аеру (табышмак, санамыш, тизәйткеч, эндәшләр һ.б.)
- тексттагы кабатлаулар, рифма, эндәш сүзләрне табу, сорау һәм өндәү җөмләләрне тану
- “Эчтәлек” битеннән кирәкле әсәрнең кайсы биттә булуын ачыклау;
- бирелгән текстка карата сорауларга җавап табу.

**Укучы түбәндәгеләрне белергә тиеш:**

- төрле авторларның 3 — 4 әсәрен яттан;
- укылган әсәрләрнең эчтәлеген.

**Мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары**

**Өстәмә әдәбият**

1. Г.Вәлиева. “Татар теленнән күнегүләр җыентыгы”.
2. Э.Б.Шакирҗанова. “Татар теле орфографиясенең кыен очраклары”
3. Ф.М.Зиннурова. “Бала сөйләмендәге кимчелекләрне төзәтү”.
4. Н.С.Гыймадиева. “Үзебез язабыз”.

***Укыту кулланмасы:***
*1) предмет рәсемнәре;*
*2) компьютердан алынган материаллар;*
*3) дидактик материаллар;*
*4) папкада җыелган материаллар;*
*5) татарча дисклар.*

**Интернет-ресурслар:**

- *Сетевое объединение методистов*

**http://center.fio.ru/som**

В разделе «Начальная школа»:

- разработки к урокам;
- новинки литературы;

***Газета«Первоесентября»***

**http://nsc.1september.ru/**

«Начальная школа»:

- Избранные материалы газеты "Начальная школа". Лучшие публикации. Методические рекомендации, сценарии уроков, примеры тематического планирования по различным учебно-методическим комплектам, сценарии праздников, олимпиады, викторины ...

***- Каталог ресурсов на Российском образовательном портале***

**http://school.edu.ru/catalog.asp**

Раздел «Начальная школа»

- Интеллектуальное развитие и обучение (материалы по предметам);
- Досуг;
- Воспитание;
- Психофизическое развитие

***Сеть творческих учителей /ИКТ в начальной школе***

**http://www.it-n.ru/communities.aspx?cat_no=5025&tmpl=com**

- Мультимедийные уроки
- Воспитательная работа
- Внеклассная работа по предметамУчебные фильмы

## ***Календарь - тематик план***

**Сыйныф:** *1*
**Укытучы:** *Калинина Мәкфия Биктимир кызы*
**Беренче яртыеллыкта**: *32 сәг.,* **икенче яртыеллыкта**: *34 сәг.*
**Барысы:** *66 сәг.*; **атнага:** *2 сәг.*

**Календарь-тематик план** ▪ *"Башлангыч гомуми белем бирү программалары"(Татар телендә гомуми белем бирү мәктәбе өчен.1-4сыйныфлар,2010 ел) , Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе "Яңа Мәлкән төп белем бирү мәктәбе"нең 2013-2014 нче уку елына укыту планына*

**нигезләнеп төзелде.**

**Дәреслекләр:**

*1.* Р.Г.Вәлитова,С.Г.Вагыйзов ***"Әлифба"*** *Казан. "Мәгари" нәшрияты. 2011*

*2.* Р.Г.Вәлитова,С.Г.Вагыйзов. ***Әдәби уку:1нче сыйныф****: дәреслек. Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2012.*

**Өстәмә әдәбият:**

1.Ф.М.Зиннурова. "Бала сөйләмендәге кимчелекләрне төзәтү".
2. Н.С.Гыймадиева. "Үзебез язабыз".

| № | Дәрес темасы | Дәрес ти-бы | Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре | | | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Предмет буенча күнекмәләр | Метапредмет нәтиҗәләре | Универсаль уку гамәлләре | план | факт |
| **Әзерлек чоры-9сәг** | | | | | | | |
| 1 | 1сентябрь-белем бәйрәме.. Сөйләм. Туган тел. Җәй. Көз. | Кат наш | Позитив аралашу кагыйдәсе.Исәнләшкәндә, саубуллашканда, үтенгәндә тылсымлы сүзләр.Ни өчен укырга кирәк? | Тыңларга һәм сөйләшергә.Аралашуның максаты. | **Р:** укытучы бәясен тыныч кабул итү.<br>**ТБ:**аралашу,танышу,мәктәп,укучы төшенчәләренең әһәмияте турында фикерләү төзү.<br>**К:**коммуникатив сөйләм гамәлләрен төзү.<br>**Ш:**мәктәп турында уңай фикердә булу,укырга телиләр.Мәктәп, дәрестә үзеңне тоту турында күзаллаулары бар. | 1.09 | |
| 2 | Җөмлә.Сүз.Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. | Кат наш | Нәрсә ул сүз? Сүзтезмә? Җөмлә? | Телдән сөйләмдә җөмләләрне аерырга. Бирелгән темага җөмләләр төзи белергә. | **Р:**информация алу һәм бирү ысулы буларак аралашу процессын аңлау.<br>**П:**төрле төрдәге кушма җөмләләрне сөйләмдә кулланырга.<br>**К:**әйләнә-тирәдәгеләргә тәэсир итүдә конструктив ысуллар төзү.<br>**Л:**үзләренеңуңышлары(уңышсызлыклары)ның сәбәпләре турында фикер йөртәләр. | 4.09 | |
| 3 | Сузык аваз. Тартык аваз. Кушылмалар. | Кат наш | Авазлар.Тартык һәм сузык авазларны аеру. | Сүзләрдән авазларны аерырга,бирелгән авазлар белән сүзләр уйларга. | **Р:** билгеле һәм белгәнне билгесез белән тәңгәлләштерү.<br>**ТБ:**иптәшләрең, укытучы алдында чыгыш ясау күнекмәсе,эшчәнлекнең нәтиҗәсе һәм ысуллары рефлексиясе.<br>**К:**үзеңнең уйларыңны коммуникация шартлары һәм бурычларына тәңгәл китереп белдерү.<br>**Ш:**үзеңнең эш-гамәлләреңне кабул ителгән кагыйдәләр нормасы белән туры китерү. | 08.09 | |
| 4 | Сузык [а] авазы, А, а хәрефләре | Кат наш | Авазлар.Тартык һәм сузык авазларны аеру.<br>Сүз моделе. Сузык [а] авазы һәм Аа хәрефләре.Сүзнең аваз моделе.Модель буенча сүзгә анализ. | Тартык һәм сузык авазларны әйтергә, авзларны ике төркемгә бүләргә. | **Р:**информация алу һәм бирү ысулы буларак аралашу процессын аңлау.<br>**П:**төрле төрдәге кушма җөмләләрне сөйләмдә кулланырга.<br>**К:**әйләнә-тирәдәгеләргә тәэсир итүдә конструктив ысуллар төзү.<br>**Л:**үзләренеңуңышлары(уңышсызлыклары)ның сәбәпләре турында фикер йөртәләр. | 11.09 | |
| 5 | Сузык [ә] авазы, Ә, ә хәрефләре. | Кат наш | Сузык [ә] авазы һәм Ә,ә хәрефләре.Сүзнең аваз моделе.Модель буенча сүзгә анализ. | Үзара аңлашу өчен предмет һәм сүзне тәңгәл китерергә кирәклеген,барлык уйларны предмет ярдәмендә әйтеп булмавын аңларга. | **Р:** билгеле һәм белгәнне билгесез белән тәңгәлләштерү.<br>**ТБ:**иптәшләрең, укытучы алдында чыгыш ясау күнекмәсе,эшчәнлекнең нәтиҗәсе һәм ысуллары рефлексиясе.<br>**К:**үзеңнең уйларыңны коммуникация шартлары һәм бурычларына тәңгәл китереп белдерү.<br>**Ш:**үзеңнең эш-гамәлләреңне кабул ителгән кагыйдәләр нормасы белән туры китерү. | 15.09 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Сузык [и] авазы һәм И,и хәрефләре. | Кат наш | Сузык [и] авазы һәм Ии хәрефләре. Сузык [ү] авазы һәм | Сүзләрдән авазларны аерырга,бирелгән авазлар белән сүзләр уйларга. | **Р:**информация алу һәм бирү ысулы буларак аралашу процессын аңлау.<br>**П:**төрле төрдәге кушма җөмләләрне сөйләмдә кулланырга.<br>**К:**әйләнә-тирәдәгеләргә тәэсир итүдә конструктив ысуллар төзү.<br>**Л:**үзләренеңуңышлары(уңышсызлыклары)ның сәбәпләре турында фикер йөртәләр. | 18.09 | |
| 7 | Сузык [ы] авазы, Ы, ы хәрефләре. | Кат на | Сузык [ы] авазы һәм Ыы хәрефләре.Сүзнең аваз моделе.Модель буенча сүзгә анализ. | Рәсем буенча хикәя төзү. | **Р:**дәреслектә ориентлашу буенча үзеңнең гамәлләреңне контрольгә алырга.<br>**ТБ:**әсәрдәге геройлар турында катлаулы булмаган монологик сөйләм төзү.<br>**К:** үзеңнең уйларыңны коммуникация шартлары һәм бурычларына тәңгәл китереп белдерү.<br>**Ш:**тырышлык һәм хезмәт сөючәнлеккә бәйләп, укудагы уңышлары (уңышсызлыклары) турында бәя бирәләр. | 22.09 | |
| 8 | Сузык [ү] авазы һәм Ү,ү хәрефләре. | Кат наш | Үү хәрефләре.Сүзнең аваз моделе.Модель буенча сүзгә анализ. | Сүзләрдән авазларны аерырга,бирелгән авазлар белән сүзләр уйларга. | **Р:** билгеле һәм белгәнне билгесез белән тәңгәлләштерү.<br>**ТБ:**иптәшләрең, укытучы алдында чыгыш ясау күнекмәсе,эшчәнлекнең нәтиҗәсе һәм ысуллары рефлексиясе.<br>**К:**үзеңнең уйларыңны коммуникация шартлары һәм бурычларына тәңгәл китереп белдерү.<br>**Ш:**үзеңнең эш-гамәлләреңне кабул ителгән кагыйдәләр нормасы белән туры китерү. | 25.09 | |
| 9 | Сузык [у] авазы һәм У,у хәрефләре. | Кат наш | Сузык [у] авазы һәм У, у хәрефләре.Сүзнең аваз моделе.Модель буенча сүзгә анализ. | Сүзләрдән авазларны аерырга,бирелгән авазлар белән сүзләр уйларга. | **Р:**дәреслектә ориентлашу буенча үзеңнең гамәлләреңне контрольгә алырга.<br>**ТБ:**әсәрдәге геройлар турында катлаулы булмаган монологик сөйләм төзү.<br>**К:** үзеңнең уйларыңны коммуникация шартлары һәм бурычларына тәңгәл китереп белдерү.<br>**Ш:**тырышлык һәм хезмәт сөючәнлеккә бәйләп, укудагы уңышлары(уңышсызлыклары) турында бәя бирәләр. | 29.09 | |
| **Әлифба чоры-33сәг** | | | | | | | |
| 10 | Тартык [л] авазы, Л, л хәрефләре. | Кат наш | Тартык [л], авазы һәм Лл хәрефләре. Сүзнең аваз моделе.Модель буенча сүзгә анализ. | Сузык һәм тартык авазларны әйтергә,авазларны ике группага бүләргә,укырга. | **Р:**информация алу һәм бирү ысулы буларак аралашу процессын аңлау.<br>**П:**төрле төрдәге кушма җөмләләрне сөйләмдә кулланырга.<br>**К:**әйләнә-тирәдәгеләргә тәэсир итүдә конструктив ысуллар төзү.<br>**Л:**үзләренеңуңышлары(уңышсызлыклары)ның сәбәпләре турында фикер йөртәләр. | 02.10 | |
| 11 | Тартык [т] авазы, Т, т хәрефләре. | Кат наш | Тартык [т] авазы һәм Т,т хәрефләре.Сүзнең аваз моделе.Модель буенча сүзгә анализ. | Сүзләрдән авазларны аерырга,бирелгән авазлар белән сүзләр уйларга. | **Р:** билгеле һәм белгәнне билгесез белән тәңгәлләштерү.<br>**ТБ:**эшчәнлекнең нәтиҗәсен һәм процессны бәяләү һәм контрольгә алу. | 06.10 | |
